ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2026 № 30

**Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү эшчәнлеген оештыру турында» 2024 елның 28 августындагы 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителә торган затларны ресоциальләштерү эшчәнлеген оештыру турында» 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү эшчәнлеген оештыру турында» 2024 елның 28 августындагы 112 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыру хакында»;

1.2. Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аларга карата пробация кулланыла торган затларның социаль тәртибен коррекцияләү, ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү, аларның яңа җинаятьләр кылуын кисәтү мәсьәләләрен хәл итү максатларында»;

1.3. 1 пунктта "Биектау муниципаль районы ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү" сүзләрен «Биектау муниципаль районында "Россия Федерациясендә пробация турында" Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга»;

1.4. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

"Россия Федерациясендә пробация турында" Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

"Россия Федерациясендә пробация турында" Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә;

1.5. 3 пунктта "Биектау муниципаль районы иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү" сүзләрен «Биектау муниципаль районында "Россия Федерациясендә пробация турында" Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга».

4. Биектау муниципаль районы иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм Биектау муниципаль районы иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүгә ярдәм итүне оештыру буенча ведомствоара эш төркеме составын (2 нче кушымта) яңа редакциядә кушымталар нигезендә бәян итәргә.

5. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Р.Ф. Хисамутдинов

1 нче кушымта

Биектау муниципаль
районы Башлыгының
2026 елның "13"март
30 нчы номерлы карары
белән расланды

# "Россия Федерациясендә пробация турында" Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының (шәһәр округының) "Россия Федерациясендә пробация турында" Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссиясе (алга таба - муниципаль комиссия) - күрсәтелгән муниципаль берәмлектә аларга карата пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптация һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләре буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы каршындагы даими эшләүче координация органы.

1.2. Муниципаль комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә пробация турында» 2023 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру турында» 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эш төркеме турында нигезләмәгә таяна.

1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы жирле үзидарә

органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

1.4. Муниципаль комиссия эшчәнлеге ресоциализацияләүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль реабилитацияләүдә ярдәм күрсәтү күздә тотылган затларның теләге һәм ихтыяр белдерү иреге принципларына нигезләнә.

## II. Муниципаль комиссиянең төп бурычлары

Муниципаль комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында хөкем ителгәннәргә, жинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән затларга һәм мәжбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән, авыр тормыш хәлендә калган затларга карата кулланыла торган чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

һөнәри ориентация һәм хезмәткә яраклашу;

торак һәм көнкүреш ягыннан урнаштырылу;

медицина ярдәме күрсәтү;

белем алу;

социаль хезмәт күрсәтүгә хокукны гамәлгә ашыру;

психологик ярдәм;

юридик ярдәм;

югалган социаль элемтәләрне һәм функцияләрне торгызуга ярдәм итү;

пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерүнең, социаль адаптацияләүнең һәм социаль реабилитацияләүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы жирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, гражданнар җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү, шул исәптән вакытлыча тору урыны бирү, пробация үзәген төзү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген һәм үзара хезмәттәшлеген координацияләүне тәэмин итү.

2.3. Пробация кулланыла торган затларның бердәм реестрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабатланучы (рецидив) жинаятьчелекне профилактикалау.

2.5. Җәмәгатьчелеккә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү буенча үткәрелә торган эшләр турында мәгълүмат бирү.

## III. Муниципаль комиссия вәкаләтләре

Муниципаль комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Ресоциализацияләүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль реабилитацияләүдә ярдәм күрсәтү турында алардан гариза килгән затларның социаль хәлен индивидуаль тәртиптә карый һәм анализлый.

3.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль реабилитация индивидуаль программасы нигезләмәләрен куллануны карый һәм анализлый.

3.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.4. Муниципаль комиссия хокуклы:

3.4.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, гражданлык җәмгыятенең башка оешмалары һәм институтлары тарафыннан үтәүгә тәкъдим ителгән карарларны үз компетенциясе чикләрендә кабул итәргә;

3.4.2. Җинаять яисә административ җаваплылыкка китерә торган законнарны бозу билгеләре ачыкланган очракта гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документлар һәм материалларны җибәрергә.

3.5. Муниципаль комиссия пробация өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз компетенциясе чикләрендә пробация субъектлары булган органнар, учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә:

3.5.1. Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (аның территориаль бүлекчәләре) белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

-хөкем ителгәннәрне, җинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән затларны һәм авыр тормыш хәлендә калган мәҗбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны пробация кулланыла торган затларның бердәм реестры операторы буларак исәпкә алу;

- башкарма яисә постпенитенциар пробация кулланыла торган затлар белән

социаль һәм тәрбияләү эше үткәрү;

ресоциализациягә, социаль адаптациягә һәм социаль реабилитациягә индивидуаль мохтаҗлыкны бәяләүне уздыру;

- аларга карата башкарма яки постпенитенциар пробация куллану турында карарлар кабул ителгән затлар өчен индивидуаль программалар әзерләү;

- пробация үзәге эшчәнлеген коммерциягә карамаган, шул исәптән дини, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан оештыру;

3.5.2. Эчке эшләр органнары белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

- башкарма яки постпенитенциар пробация куллану;

- индивидуаль профилактик эш үткәрү;

- хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

- хөкем ителүчене Россия Федерациясе гражданы паспорты белән документлаштыру;

3.5.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау муниципаль районындагы һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районындагы халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендәге социаль яклау бүлеге белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

- халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау (хезмәт күрсәтү) өлкәсендә, шул исәптән мәҗбүри эшләр яисәирегеннән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшкә урнашуда ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

- мәҗбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга карата эшкә урнашу һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә статистик мәгълүматны исәпкә алу;

- билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәтләр алучылар белән социаль адаптация үзәкләрендә профилактика эше;

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаганнарны, шулай ук иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль адаптацияләү;

- булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында, хезмәт шартлары турында, хезмәт хакы турында һәм вакансияләр эзләүчеләргә карата квалификация таләпләре турында мәгълүмат бирү юлы белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль реабилитацияләүгә ярдәм итү;

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга эшчәнлек

өлкәсен (һөнәр) сайлау максатларында һөнәри ориентация, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган күрсәтелгән категориядәге затларга һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

- эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, социаль адаптация буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштыручы эш бирүчеләрне стимуллаштыру;

3.5.4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Биектау район үзәк хастаханәсе» ДАССУ белән беренчел медицина-санитария ярдәмен, профилактика һәм диспансер күзәтүен оештыру мәсьәләләре буенча;

3.5.5. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф һәм фән бүлеге» МКУ белән гомуми белем, урта һөнәри белем алу, һөнәри өйрәнү узу мәсьәләләре буенча;

3.5.6 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында клиент хезмәте хокукларында Россия Федерациясе Социаль фонды бүлеге белән индивидуаль лицевой счет ачу һәм индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәп системасында теркәлүне раслый торган һәм индивидуаль лицевой счетның иминият номеры турында белешмәләр булган документны рәсмиләштерү мәсьәләләре буенча, пенсия тәэминаты алуда (аны алу хокукына ия затлар өчен);

3.5.7. Дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнар җәмгыяте оешмалары, институтлары белән аларның компетенцияләре нигезендә.

## IV. Муниципаль комиссияне формалаштыру тәртибе

4.1. Муниципаль комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында формалаша.

Муниципаль комиссия рәисе:

- Муниципаль комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

-хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, Муниципаль комиссия утырышларын алып бара;

- Муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

- үз вәкаләтләре кысаларында Ведомствоара комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

- Муниципаль комиссия кабул итә торган документларга имза куя;

- Муниципаль комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Муниципаль комиссия рәисе урынбасары:

- комиссия рәисе кушуы буенча ул булмаганда Муниципаль комиссия

рәисе вазыйфаларын башкара;

- Муниципаль комиссия карарларының үтәлешен тикшереп тора;

- ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек эшләве тотрыклылыгын арттыру чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыра.

Муниципаль комиссия секретаре:

- Муниципаль комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

- Муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен төзи, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен җайга сала, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

- Муниципаль комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга Муниципаль комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат бирә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

-Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарына затның киләчәктә азат ителүе, аның торагы булуы, хезмәткә сәләте һәм булган белгечлекләре турында җәзаны үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән керә торган мәгълүмат җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализацияләүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль реабилитацияләүгә ярдәм итү турында гаризалар кабул итә;

- ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль реабилитация программасының һәр катнашучысына озата бару картасын һәм шәхси эшне рәсмиләштерә, аңа индивидуаль программа чараларын үтәү буенча документлар һәм белешмәләр кертелә;

- "Пробация кулланыла торган затларның бердәм реестры" дәүләт мәгълүмат системасының муниципаль сегментын алып бара;

- муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан Муниципаль комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып ала;

- Ведомствоара комиссия утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә;

- Муниципаль комиссия рәисенең аның утырышлары нәтиҗәләре буенча бирелгән йөкләмәләрен үтәүне оештыра;

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы халкына Муниципаль комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Муниципаль комиссия составы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы күрсәтмәсе белән раслана.

4.3. Муниципаль комиссия составына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау оешмалары, мәгариф оешмалары вәкилләре (килешү буенча) керергә мөмкин.

4.4. Муниципаль комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциализацияләүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль реабилитацияләүдә уңай тәҗрибәсе булган затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Муниципаль комиссия утырышларында Биектау муниципаль районы прокуратурасы вәкиле (килешү буенча) катнашырга хокуклы.

4.6. Муниципаль комиссия утырышларына Муниципаль комиссия составына керми торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, гражданнар җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.7. Муниципаль комиссия эшендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## V. Муниципаль комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Муниципаль комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. Муниципаль комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализациягә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль реабилитацияләүдә ярдәм итү турында гаризалар кергән саен, әмма елга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә үткәрелә. Кирәк булган очракта, Муниципаль комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук Муниципаль комиссия әгъзасы (рәис белән килештереп һәм Муниципаль комиссия секретаре тәкъдиме буенча) инициативасы буенча Муниципаль комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Муниципаль комиссия утырышын Муниципаль комиссия рәисе, ә ул булмаганда яки аның кушуы буенча – Муниципаль комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5.4. Муниципаль комиссия утырышы, анда составының яртысыннан артыгы катнашу шарты белән, вәкаләтле булып тора.

5.5. Муниципаль комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия һәм утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

5.6. Муниципаль комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.7. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән зат теләге буенча

утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча уздырыла.

5.8. Муниципаль комиссия әгъзалары комиссия утырышында тикшерелгән мәсьәләләр турында мәгълүматларны әлеге мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны тараткан өчен Муниципаль комиссия әгъзалары закон нигезендә җаваплы.

5.9. Муниципаль комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатында, Муниципаль комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.

2 нче кушымта

Биектау муниципаль районы
Башлыгының 2026 елның
"13"март 30 нчы номерлы
карары белән расланды

**"Россия Федерациясендә пробация турында" Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Эш төркеме җитәкчесе: | |
| Хәкимуллин Рамил Фатыйх улы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе. |
| Эш төркеме җитәкчесе урынбасары: | |
| Сабирҗанов Ринат Рәшит улы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары. |
| Комиссия секретаре: | |
| Газизов Рафис Гарәфи улы | «ТР МТЗ һәм СЗ Биектау муниципаль районында «Өмет» КЦСОН» ГАУСО директоры |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Абрамов Артем Анатольевич | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы (килешү буенча); |
| Гайфуллин Айрат Нурислам улы | -«Биектау район үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Сөнгатуллин Рим Фәргать улы | - Биектау муниципаль районы прокуроры (килешү буенча); |
| Корбанов Фәрит Нурәхмәт улы | - «Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча) |
| Минаева Гүзәл | - Биектау муниципаль районында Татарстан |

| | |
|---|---|
| Равил кызы | Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Газина Әлфия Фоат кызы | - Биектау районында ТР буенча Россия УФСИН 10 нчы МРУИИ ФБУ башлыгы (килешү буенча); |